*Көлү – сихәт, көлеп яшәү мәслихәт!*

ISSN 0136-7110

# Чаян



САТИРА һәм ЮМОР ЖУРНАЛЫ МАРТ • 2022 • КАЗАН

3



Елена ХИТРОВА

Дәвамы 20 нче биттә.

Алмаз ХӘМЗИН

## ИЛАҺИ ЗАТЛАР СЕЗ!

Безнең өчен Сез – чалт Кояш!
Җылытасыз җаннарны.
Ал язмышка нурлар сибеп,
Аттырасыз таңнарны.

Безнең өчен Сез – күктә Ай!
Шәме төнге дөньяның.
Караңгылыктан ачасыз
Туры юлын кыйбланың.

Безнең өчен, йолдыз булып,
Җемелдисез йөрәктә.
Яшәү рәхәте сулкылдый
Кайгы китә күк мәрткә.

Безнең өчен җил чыгарып,
Искәләп тә куясыз.
Назлы дулкын иркәләвен,
Сөю диеп тоябыз.

Безнең өчен каен да Сез,
Ап-ак зифа гәүдәгез,
Яшел яулык бөркәнсәгез,
Чибәрлектә тиңдәшсез.

Җир йөзендә чәчәкләр күп,
Сез дә шулкадәр җирдә.
Чагыштыру мөмкин түгел,
Сез чибәррәктер дә!

Сез – яз безнең күңелләрдә:
Гөрләвекләр, ташкыннар,
Умырзая, бөре, тургай,
Сыерчыклы җыр-моңнар...

Сез – җәйге ямьлелек безгә,
Яшенле күк күкрәүләр!
Шул ләззәтнең җаен табып,
Шатлану, үкенүләр...

Сез – көзнең алтын сарысы,
Сагышы һәм муллыгы.
Сез бәхетнең иң зурысы –
Ир-атның тулылыгы!

Ап-ак кышның салкынында
Өшеткәләп аласыз.
Энҗе кардай, ялт-йолт килеп,
Күзләр сирпеп каласыз.

Без чәчәк тә түгел, Ай да,
Йолдызлар да түгел шул...
Сезнең янда матур сайрап
Йөрүчеләр генә шул!..

Сездәй илаһи затларга
Гына хас мондый сыйфат!
Шуңа күрә бит инде без
Яшибез Сезне сыйпап!..

Валерий ТАРАСЕНКО




## ШОМБАЙ болай диде...



Хөрмәтле Чаян! Мәскәү, тузан суырткыч шикелле, регионнардан хезмәт ресурсларын үзенә тарта. Акыллы, белемле һәм өметле егет-кызлар, «Иленнән аерылган – канаты каерылган» дигән әйтемне онытып, «бәхет кошы» артыннан Мәскәүгә очалар. Ә башкала аларның барысын да колач җәеп каршыламый шул...

**М. ВӘЛИЕВА**

ТҮБӘН КАМА

Укучыбызның хаты Шомбай агада кызыксыну уятты.

**– Әйе, башкалада мөмкинлекләр җитәрлек,** – диде аксакал. – **Әнә, күршем бер ел элек кенә Мәскәүгә инженер булып киткән иде, ә хәзер инде өйгә ризык китерүче курьер булып эшли...**

## КЫШКЫ ЯҢГЫР

...Яз яңгыры кояш белән килә,
Яшәү көче биреп дөньяга.
Җәйге яңгыр шифа булып төшә
Сулган гөлгә, шиңгән яфракка.
Көз яңгыры соры төсләр белән
Йөрәкләргә өсти моңсулык.
Юеш яфрак – алтын җәймәләре
Күңелләргә тула җыр булып.

...Соңгы фасыл исә, оялмыйча,
Җәеп шәрә болын һәм кырын,
Табигатьнең кануннарын бозып,
Ишеп коя кышкы яңгырын...

• • •

...Гаиләмдә әйдәп баручы мин,
Үзем тыйнак, гади, җор телле –
Бүрәнәнең җиңел башын тоткан
Өмәдәге Ленин шикелле...

Ринат АБЗАЛОВ







Александр ШУЛЬПИНОВ

# Инвалидлар үрчетү бизнесы

Андыйлар турында, халык әйтемен файдаланып, "кием бирсәң, туза, акча бирәң, аза", дип әйтергә була торгандыр. Әгәр совет замнында җиңел акча табарга омтылу зәгыйфь тырмашуга гына кайтып калган булса, бүгенге капитализм дөньясында кайберәүләр өчен бу тормышның аерылгысыз өлешенә әйләнде. Үткенлектә тиңе булмаган шома "эшмәкәрләр", җинаять кодексы статьяларына исләре китмичә, акчаны бөтен нәрсәдән ясыйлар. Хәтта инвалидлык бирү дә үтемле товарга әверелде. Группа иясе күпсанлы ташламалар белән файдалана бит: ЖКХ түләүләре, транспортта йөрү, салымнардан азат ителү, пенсиягә өстәмә дисеңме... Аларны "йотып" барырга тазалыгың гына җитсен.

Дагстандагы ялган инвалидлар вакыйгасы бөтенебезнең дә исендәдер. Алты меңнән артык чәчрәп торган таза кеше ивалидлык пенсиясе алып, ташламалардан файдаланып яткан. Зәңгәр таулар илендә ялган белешмәләр сату искиткеч киң колач алган булган.

Ә Ростов өлкәсенең Гуково дип аталган шахтёрлар шәһәрчегендә җирле эксперт, түләү бәрабәренә, барлык теләүчеләргә документлар ясап утырган. Киң күңелле табиб янына халык бөтен илдән агылган, кыйммәтле кәгазьне алу өчен вакытлы пропискага басарга гына кирәк булган. Тора-бара бу "изге" эшкә медик-социаль экспертиза хезмәткәрләре дә кушылган. Ростов осталары ясаган инвалидларның саны 10 меңнән артып киткән!

Сау-сәламәт кешене эшкә яраксыз гарипкә әверелдерү – озак һәм катлаулы эш. Мондый сихри үзгәрешнең бәясе дә аз түгел – күңеленә хуш килгән авыруга карап, 700 мең сумга кадәр. Әлбәттә, кул һәм аякны кисү турында сүз бармый. Монда кеше күзенә ташланып тормый торган авырулар гына файдаланыла.

Күптән түгел Татарстанда сенсацияле хәл ачыкланган – 13 бичара "ашказанында 4 нче стадиядәге яман шеш" диагнозы белән ничәмә еллар яшәгән. Тормышта очрамый торган – озакка сузылган ремиссия белгечләрне бик кызыксындырган. Ләкин, кызганычка каршы, медицина фәне әле мондый зур адым ясамаган – авыруларның барысы да сатып алынган белешмәле ялган инвалидлар булып чыккан. Бу тарих быел да кабатланган. Республикада тагын 35 тән 68 яшькә кадәрле 20 ялган инвалид табылган. Алар берничә ел дәвамында тиеш булмаган ташламалардан файдаланган. "Мескенкәйләр" бюджетны 7,2 миллион сумга бөлдерергә өлгергән.

Ә менә чын инвалидларга үзләренең хезмәткә яраксызлыгын ел саен исбатлап торырга туры килә – беренче килүдә үк сроксыз кәгазь алуга бик сирәге генә ирешә. Экспертиза комиссиясендә киләчәккә чиктән тыш ышану белән караучылар утыра, күрәсең. Авыруның могҗизалы рәвештә терелүенә йә югалткан кул-аякның яңадан үсеп чыгуына өметләр баглап, инвалидларны ел саен кабинеттан кабинетка йөрергә мәҗбүр итәләр. Мондый хәлдә булган һәр кеше белә – авыруыңны дәлилләр өчен, атныкыдай тазалык кирәк...

Ике ел чамасы элек илне берәзлексез ялган инвалидлар белән тәэмин итеп торучы медик-социаль экспертиза хезмәткәрләренә ау башланды. Бары Мәскәүдә генә бернинди дә авыруы булмаган, ләкин аңа карамастан, инвалидлык группасы белән яшәүче 230 мең "гарип" табылган. Кызганыч, табибларны оят та, эштән чыгару куркынычы да, җәза да туктатмый – бизнесы бик керемле шул. Сорау туып торганда, тәкъдиме дә һәрвакыт булып тора, бу – теләсә нинди бизнесның төп законы, хәтта ул "инвалидлар үрчетү" булса да.

**Людмила САФИУЛЛИНА**






Михаил ЛАРИЧЕВ




Виктор ФЁДОРОВ




Валерий ТАРАСЕНКО




• • •

Эскәмиядә утырган ике әби соңгы яңалыкны чәйни – губернатор ришвәт алганмы, әллә аңа яла якканнармы? Уртак фикергә килгәннәр: әгәр яла ягылган булса – утырталар; ришвәт алган очракта – чыгаралар.

• • •

Интернет браузерларындагы "Тарихны чистарту" төймәсе, гаилә психологларына караганда, гаиләләрне таркалудан күбрәк коткарып калган.

• • •

Берничек тә аңлый алмыйм, әгәр депутат халык хезмәтчесе икән, ул хезмәтченең нинди кагылгысызлык хокукы булсын?

• • •

– О! Директор яңа машина сатып алган! Хәзер килер дә сөйли башлар инде: янәсе, илдә – кризис, шуңа күрә ул безнең хезмәт хакларын киметергә мәҗбүр!

• • •

– Хатын-кызның игътибарыннан, иркәләү-назлавыннан башка кыен миңа, аңлыйсыңмы?

– Соң, тап үзеңә берәрсен.

– Ә хатынны кая куйыйм?

• • •

Тырышып эшләсәң байлыкка күмеләсең, күтәренке хәлдә буласың, диләр. Әмма моның депрессиягә, тынычлыгыңны югалтуга һәм организмның арып эштән чыгуы турында әйтмиләр.

• • •

– Этем мине үлемнән саклап калды.

– Ничек итеп?

– Мин каты авырып ятканда табибны өйгә уздырмаган.

• • •

– Кайсы яхшырак: ахмак булумы, пеләш булумы?

– Ахмак булу, әлбәттә. Анысы артык күзгә ташланмый.




## БРОКЕР-ДЕПУТАТ

Татарстанда Югары Ослан районының Октябрь авыл советы депутаты Артур Назаровны тоткарлаганнар. Халык хезмәтчесе Интернетта акча эшләргә тәкъдим иткән, инвестицияләрдә катнашырга чакырган. Килгән суммаларны "брокер"лар үз счётларына күчереп барган. Ә акча салучылар исә төп башында утырып калган. Шушы ысул белән депутат иптәшләре белән 5 миллион сум акча эшләгән.

## СТУДЕНТЛАР ФИКЕРЕ


Казан федераль университеты Россиянең соңгы биш ел эчендә төзелгән проблемалы вузлар исемлегенә кергән. Университет студентларының 80 проценты вузга тискәре бәя биргән. Белем алу сыйфаты мөмкин булган 10 баллдан 4,55 кә билгеләнгән, житәкчелекнең эше 4,59 баллга лаек булган. Рейтинг төзүдә 300 дәүләт вузы катнашкан.


## КҮҢЕЛСЕЗ АЛДЫНГЫЛЫК

"Русский стандарт" банк аналитиклары фикеренчә, ил буенча иң югары торак-коммуналь түләүләр Чаллыда икән – аена 4772 сум тәшкил иткән. Чаллыдан соң 3880 сум белән Төмән бара, ә инде аннан соң Мәскәү – 3475 сум. Чаллыда яшәүчеләр алдынгылыкны, шатланып, башка шәһәрләргә бирергә әзер югыйсә, әмма жирле коммуналь хуҗалык әһелләре беренче урын белән аерылырга теләмиләр бугай.

## НОМЕРЛЫ ХЕЗМӘТ

Чаллыда "Челны-МПК" ит эшкәртү предприятиесендә хезмәткәрләргә номерлар сугылган башлыклар кидергәннәр һәм аларны күзәтү өчен камералар урнаштырганнар. Шулай итеп, житәкче абзыйлар һәркемнең куйган хезмәтенең күләмен исәпләп торалар. Хезмәт хакы да шуннан тора. Житәкчелек белдерүенчә, "башлык проекты" хезмәт житештерүчәнлеген 15 процентка күтәргән. Иҗтимагый челтәрләрдән файдаланучылар бу яңалыкка югары бәя биреп, барлык депутатлар, чиновникларга да шундый номерланган башлыклар кидертергә тәкъдим иткәнәр.


Валерий ТАРАСЕНКО


Виктор ФЁДОРОВ


Валентин ДУБИНИН

# *Хатын-кызлар бәйрәменә – шаяртулар бәйләме!*

• • •

Ике дус очрашканнар.

– Хәлләрең ничек, Мәхмүт!

– Шәптән түгел шул, дускай. Хатынның күзенә пычкы чүбе эләккән иде, шуны дәвалап интектек. Табиб 5 мең сум алды.

– Синең чыгым пүчтәк ул. Кибеттә йөргәндә минем хатынның күзенә импортный тун эләккән иде, 50 мең сум чыгарып салырга туры килде...







Александр ШУЛЬПИНОВ





## ЧАЯН ШИФАХАНӘСЕ

### ИГЪТИБАР!

Фитнес үзәкләрендә VIP-абонементлар барлыкка килгән. Алар белән снарядларда изаланып, тренажёрларда тир түгәргә туры килмәячәк. Тәҗрибәле инструкторлар сезнең өчен барысын да эшләячәк. Мускуллардан гына торган гәүдәгезнең бер кул белән генә турникта күтәрелеп, бармакка гына таянып торучы фоторәсем моның өчен бонус-бүләк булачак. Тәнегездә энҗедәй тир бөртекләре җемелди, мускуллар уйнап тора! Әгәр кинәт кенә хатыныгыз шалтыратса – бәрхеттәй ир тавышы җавап бирәчәк: «Мәхмүт Кадыйрович хәзер бассейнда, ике сәгатьтән чыгачак, аңа нәрсә дип әйтергә?»


Сәламәт тормыш белән яши башларга ашыгыгыз!




Виктор ФЁДОРОВ




Анастасия ВАСИЛЬЕВА




Игорь КИЙКО

Әхәт САФИУЛЛИН

# АҢЛАДЫҢМЫ?!

Табиб бүлмәсенә пациент килеп керә.

– Керегез! Утырыгыз! Нәрсәгә зарланасыз? Аякларыгыз авыртамы? Ничек авырта: кисәк кенә башланамы, әллә сызлыймы? Аңлашылды. Ә травматолог нәрсә ди? Ә сез терапевт, окулист, наркологта булдыгызмы? Ничек инде, "нинди эше бар"? Беләсегез килсә, авыру, кешенең эчке органнары кебек, бер-берсе белән тыгыз бәйләнештә. Аңлашыламы? Мәсәлән, кеше начар күрә, ди. Урамнан барганда ялгыш басып аягын сындыра. Аңлашыламы? Шуңа күрә иң башта күзләрне, авыз, борын, колак, йөрәк, бавыр, ашказанын тикшертергә кирәк... Ә аннан соң инде минем янга рәхим итегез! Дәваларгамы, шунда ук кисеп ташларгамы — хәл итәрбез... Аңладыгызмы? Ә хәзергә хушыгыз!

Тагын бер ханым килеп керә.

– Керегез, ханым, керегез! Утырыгыз! Нинди зарларыгыз бар? Корсак асты авыртамы? Аңлашыла. Дөрес кергәнсез! Чишенегез. Юк-юк, бөтенләй түгел, билгә кадәр генә... Ятыгыз! Болай авыртамы? Ә болай? Билдән башлап авырта, дисезме? Аңлашыла. Ә билегез кай төштәрәк соң сезнең? Аңлашыла. Бусер түгел микән бу? Бик мөмкин. Сезгә терапевт, невролог, пульмонолог, окулистка күренергә кирәк. Аңлашыламы? Ничек инде нәрсәгә? Бөтен мәсьәләләрегезне берьюлы хәл итү өчен. Сезгә бит әле яшисе дә яшисе! Алтмыш яшь ул күп түгел әле. Утыз ике генә, дисезме? Ни булса да, яхшы саклангансыз! Димәк, болай: бөтен мин әйткән табибларны йөреп чыгасыз да, минем янга киләсез! Анда инде карарбыз — тикшерербез, өйрәнербез, кирәк булса кисеп ташларбыз. Аңлашылдымы? Хушыгыз!

Пациентны озаткач, табиб ширма артына керә.

– Ничек, бәхәсне оттым бит! Табиб түгеллегем берсенең дә башына килмәде! Шуңа күрә минем алда медицина университеты дипломы белән мактанасы булма! Менә мин, слесарь-сантехник, синең урында эшли алам икән бит. Кайда өйрәндемме? Синнән өйрәндем дә инде! Исеңдәме, аягыма чуан чыккач, син мине табиблар буенча җибәрдең. Барысын да йөреп чыкканчы, ул үзе бетте. Шәп ысул бит! Давай, коньякка чап, коллега! Аңладыңмы?







Ләбиб ЛЕРОН

# Марсель Галигә... һәйкәл?

Дөньяның иң бай кешесе, түбәндәге сүзләрен әйтер өчен генә дә, татарча сөйләргә өйрәнеп:

– Марсель Гали әфәнде, ун томлык китабыңны супертышлык белән иң затлы кәгазьдә, иң зур тираж белән, иң данлыклы типографиядә нәшер кылдырып бирәм, үзеңә фәлән-фәлән миллион доллар гонорар түлим, туган ягың Азнакайдагы Чатыр тауга үземнең дә төшкә кермәгән вилла салдырып, үзеңне Җир шарына мәшһүр итәм, әгәр дә син бер генә көн булса да телефоннан сөйләшмичә һәм үз-үзеңне мактамыйча торсаң, – дисә дә, Марсель Гали барыбер телефоннан сөйләшер, үз-үзен мактар иде.

Менә әле дә ул "Салават күпере" журналы редакциясенең баш мөхәррире Зиннур Хөснияр телефонының санлы тәгәрмәчен озынча имән бармагы белән зырылдата-зырылдата, телефон көпшәсенең тыңлый торган өлешен авызына, сөйләшә торганын колагына терәп сөйләвен белә:

– Ризван Хәмиднең – Язучылар берлегендә урынбасар, минем һөнәрмәнд, ягъни профессиональ язучы буларак беркайда да эшләмәгән чак. Рөстәм Мингалимне дә алып, киттек без Горький паркына очрашуга. Халык, мин киләсен әллә каян ишетеп-белеп, шактый җыелган иде. Минем затлы сүзләрне зар-интизар булып тыңларга әзерләнгән шул халыкны Ризван Хәмид иң әүвәл үзе белән таныштырды: "Язучылар берлеге рәисе урынбасары, идарә әгъзасы, М. Җәлил исемендәге комсомол бүләге лауреаты, танылган драматург – "Китәм инде", "Кайтам инде", "Китмимен дә, кайтмыймын да", "Әллә китәргә микән?", "Бәлки, тагын кайтырмын" кебек чутсыз пьесалар авторы..." Ризван, пьеса исемен әйткән саен, халыкка: "Бәлки, карагансыздыр спектакльне?" – ди. Миңа мөкиббән булып утырган халык – ләм-мим. Аптырагач, Ризван Хәмид халыкка мине тәкъдим итәргә кереште: "Марсель Гали – шагыйрь, прозаик, бик күп китаплар авторы, Язучылар берлеге каршындагы бердәнбер стена газетасының баш мөхәррире..." Шуның белән вәссәлам! Ә халык... Ә халык гөрләтеп кул чаба! Луиза Батыркай җырга әйләндергән "Су буеннан әнкәй кайтып килә" дигән мәшһүр шигыремне укыгач, халык, сагышлы күз яшьләрен импортный күлмәк җиңнәре, күпсанлы һинд яулыгы читләре белән сөртә-сөртә, отыры күңелле гөжләргә тотынды...

Әлеге очрашу хакындагы хикәятне инде туксан бер мәртәбә бирелеп тыңлаган каләмдәшләренең монысында битараф кына колак салып, үзара ни турындадыр гәпләшеп утыруын күргәч, Марсель Гали, төтен чыгар дәрәҗәгә җиткән телефонны янә тетрәтә-тетрәтә, үпкәчел тавыш белән:

– Белмисез бердәнбер затлы язучыгызның кадерен. Бөек башым белән сезнең янда йөргән мин җүләр!..

Мөһим эше буенча телефоннан шалтыратырга интегеп, бу хакта Марсель Галигә әйтергә кыенсынып утырган Зиннур Хөснияр:

– Әле генә Сәйдәшкә җыеп туктаган идек. Тагын һәйкәлгә акча җыясы була икән, – ди.


Николай ЧЕРНЫШОВ

## СҮЗ ИЯРӘ – СҮЗ

• Барысы да дөреслек табарга тели, ә аны эзләргә кирәк тә түгел.

• Әгәр тиле ярарга тырыша икән, димәк, ул шыр тиле түгел.

• Кеше булу гына җитми, кирәкле кеше була белергә кирәк.

• Уйлый башлаганчы, яхшылап уйлап карарга кирәк.

• Кайчагында дөреслек булырга лаек ялган да очрап куя.

• Хакимиятне хакимлеккә менеп җитә алмаганнар ныграк куралмый.

• Без шулхәтле озак җигәбез ки, җиккән арада кузгалуның мәгънәсе дә юкка чыга.



Александр АЛЁШИН

Нури БУРНАШ

## Шәхси эш

Сөйкемле кыз шыплап тулган маршрут автобусында дулкынланган тавыш белән телефоннан сөйләшә. Вакыты-вакыты белән кычкыруга күчүенә караганда, аның әңгәмәдәше ниндидер шахтада иде, ахрысы. Пассажирлар инде егерме минут чамасы бу әңгәмәгә тулы битарафлык күрсәтергә тырышып утыралар иде. Аның каршысында утырган абзыйның йөзендә генә сөйләшүнең бөтен кискен борылышлары көзгедәге кебек чагылып бара. Кыз аңа игътибар итми: шахтёрга кычкырганда, тирә-юньгә борылырга ярамый бит.

– Синең аркада, – дип дәвам итте ул бушлыкка карап, – бөтен шәһәр безнең мөнәсәбәтләр турында белеп тора! Аңлыйсыңмы, бөтен шәһәр! Син безнең уртак мәсьәләләр турында теләсә кем белән сөйләшеп йөрисең. Теләсә кем белән, дим! Минем иң яшерен...


Кыз, җавап тыңлау өченме, бераз туктап торды. Каршыдагы абзый, колагын тырпайтып, катып калды. Автобус йөртүче тукталышны игълан итәргә онытты. Салон бүенча дөбершатыр килеп чебен очып узды. Ярты минуттан әңгәмә дәвам итте, салон җиңел сулап куйды.

– Бөтенесе дә безнең гаилә тормышына борынын тыга! Минем тормышка! Тормышка, дим! Синең әниең, минем әни, барча туган-тумача, шатланып, безнең аерылышуны чәйни. Аерылышуны гына түгел, аның сәбәбен дә. Ә анда беркемнең дә эше юк бит. Беркемнең дә!

Автобус тынып калды. Кондуктор талоннар рулонын төшереп җибәрде һәм мыгырданып, идәндә аны эзли башлады. Халык аңа усал итеп карап куйды. Студент университет тукталышында автобустан төшми калды. Каршыдагы абзыйның йөзе тагын да киеренкеләнде.

– Тиздән синең аркада йөземне яшермичә эшкә дә йөри алмый башлаячакмын! Кабахәтлек бит бу, ишетәсеңме? – кыз усал зәңгәр күзләре белән тәрәзәгә карап алды. – Бу кайчан да булса бетәчәкме? Бетәчәк, дип сүз бир!

– Ант итәм! – дип кычкырды кинәт каршыдагы абзый, кулын йөрәгенә куеп.



Михаил ЛАРИЧЕВ




Николай ВОРОНЦОВ



Валерий ТАРАСЕНКО

Гүзәл СӨНГАТУЛЛИНА

## МӨСЛИМНӘН КИМ ТҮГЕЛ ИКӘН ХӘМЗИН...

Балачагымда әнием аяк киеме складында эшләп алды бераз. Өйгә якын булгач, безне озакка ялгыз калдырмас өчендер инде. Ул складтан җыен дефицит аяк киемен генә алып була иде. Гади халыкка тимәде андый нәрсәләр.

Көннәрнең берендә, кич белән әнием белән әтием сөйләшеп утырганы истә калды:

– Бүген безнең складка Мөслим Магомаев килде. Әй, күрсәң инде бездәге хатыннарны!.. Артыннан өелешеп йөриләр. Сүз кушалар, елмаялар, – ди әнием. – Их, ичмасам, бер кочаклап үбәргә иде, – дип тә куялар. Бигрәк сәер инде кыланышлары. Артистларны күргәч башларын югалталар.

– Ә ул нәрсә? – дип сорап куйды әтием.

– Нәрсә ул? Ул бөек, танылган кеше. Аңа мондый хатыннар кирәкмени?.. Шул инде. Бераз күңелләре булсын дип елмаеп куйды. Үзенә кирәкле аяк киемен сайлады да, машинага утырып китте...

Бу хәлнең ник исемә төшкәнен хәзер аңлатам...

«Чаян» журналында озак еллар эшлим инде. Күптән түгел бездә ремонт булды. Шуннан соң бер бүлмәгә Алмаз абый Хәмзин белән бергә туры килдек.

Күңелле аның белән эшләү. Яңа җырын язса, җырлап та ала, шигырьләрен укый. Уртак фикерләребез дә күп икән.

Кайбер таныш дусларым, бүлмәдә кем белән утырганымны белгәч, нәкъ теге әнием белән эшләгән хатыннар шикелле, акылдан шаштылар.

– Карале, син нинди бәхетле кеше икәнсең бит – нинди данлыклы, зур кеше белән бергә эшлисең, – ди берсе.

– Кайчагында шигырьләре бик усал була, үзе ничегрәк соң? Усал кеше түгелме? – ди икенчесе.

– Концертлары булганда безгә пригласительный сора әле, сиңа авыр түгелдер инде алуы? – дип куя өченчесе.

Ничек аңлатыйм соң мин аларга? Без бергә эшлибез. Кеше концерт уздыра икән, димәк, ул концертларга билетлар сатыла. Кассага барыгыз да алыгыз, барасыгыз килсә. Чакыру билеты алырга теләүчеләре үзенең дә күптер.

Шулай дигәч үпкәлиләр:

– Сиңа рәхәт, син аны көн саен күрәсең. Яңа җырларын да тыңлыйсың. Ичмасам, безгә бер фотосын гына да җибәр инде. Автографы белән.

– Ирләрегез ни дип әйтер, фотосын күрсә?

– Безнең дустыбыз шундый кеше белән бергә эшли дип, горурланырбыз, – диләр.

Менә бит, чыннан да, нинди бәхетле кеше икәнмен!




## КОТЫРГАН ПРОЦЕНТ

РФ Генераль прокуратурасы азык-төлек продуктларына бәяләрне күзәткән һәм күп кенә кызыклы нәрсәләр тапкан. Мәскәүдә, мәсәлән, 46 сум урынына 81 сумлык шикәр тапканнар. Калуга өлкәсендә сөт, кефир һәм онны өчләтә арттырып сатканнар, Якутиядә – ярмалар һәм йомырканы, ә Бурятиядә бер институтның хаерче студентларына ашны бәясеннән 295% ка кадәр арттырып сатканнар. Узган ел бу өлкәдә барлыгы мең ярым хокук бозу очрагы ачыкланган. Бәяләрне кулда тоту өчен, прокурорлар сәүдә оешмаларына 2 меңгә якын кисәтү ясаганнар.

## ЙОРТ ТУЛЫ КЕШЕЛӘР

Алтайда элеккеге Бийск районы башлыгының урынбасарын хөкем итәчәкләр. Боровой бистәсендәге бер йорт җимерелү куркынычы аркасында авария хәлендә дип табылган. 18 гаиләне, администрация фикеренчә, торырга яраклы урынга – тулай торакның яшәүгә яраксыз булган бинасына күчергәннәр. Яңа йортта батареялар да, кухня да, бәдрәф тә юк, ә тәрәзәләре фанера белән кадакланган. Прокуратура торак шартларын сәер рәвештә яхшырту белән кызыксынган. Әмма түрә үз гаебен танымаган, районның башка финанс мөмкинлекләре булмавы белән акланган.

## КАДЕРЛЕ ХӘТЕР

Ростов өлкәсенең Приморка авылында Бөек Ватан сугышы солдаты һәйкәле янында мәңгелек утны аның рәсеме төшерелгән монитор белән алыштырганнар. Хакимият тә мондый альтернативаны бик лаеклы дип саный, чөнки авыл җирлеге башлыгы сүзләренә караганда, ут бик кыйммәткә чыга. Заманча техниканың ни дәрәҗәдә мәңгелек булачагын вакыт күрсәтер.

## «Ё»!

Чиләбедән күп балалы ананы «ё» хәрефе аркасында ана капиталыннан мәхрүм иткәннәр. Өченче баласы тугач, ул тиешле түләү сорап пенсия фондына мөрәҗәгать иткән. Әмма белгечләр өлкән балаларның фамилиясендә туу турындагы таныклыкларында «ё» хәрефе, ә яңа туган баланың «е» хәрефе торуын ачыклаган. Шуның аркасында күп балалы әнигә сертификат бирүдән баш тартканнар.







## СОРАУ – ҖАВАП

– Әти, ә зоопарк нәрсә ул?
– Ул – хайваннарны кешеләрдән саклый торган урын.

• • •

– Алло, сантехникмы бу? Безнең краннан су агып тора!
– Ә сезнеңчә аннан нәрсә агарга тиеш?

• • •

– Әлек сине гел бер кыз белән күрә идем, ә хәзер ялгыз да, ялгыз?
– Мин аңа өйләндем шул...

• • •

– Официант, нигә китергән бу тавык шыр сөяктән тора?
– Модасы шундый, бар да ябыгырга тели.

• • •

– Ат кайчан эшләүдән туктый?
– Урынына дипломлы яшь ишәк килгәч!

Илья КРИШТУЛ

# Ничек бай һәм сәламәт булырга

Беренчедән, өйдә сызгырырга ярамый. Беркайчан да! Икенчедән, өйдән чыкканда табан астыгызга һәрвакыт лавр яфрагы салыгыз. Беләсезме, минем бер танышым ничек баеды? Берзаман ул кунакка барган, табан астына лавр яфрагы куеп, әлбәттә. Ике Борис арасына утырган һәм теләк баглаган. Бары шул гына! Тегеләре, әйтергә кирәк, бик ачык күңелле булып чыкмаганнар, ләкин ике Владимир арасына утырсаң да ярый бит. Иң мөһиме: шул чакта сулы стаканга көмеш тәңкә салырга һәм "Әфсен-төфсен, акчам күбәйсен!" дип әйтергә генә кирәк. Стаканны өеңә алып кайтырга, ә аннан соң тәңкәне мендәр астына салып куясы гына кала. Ә үзегез, диванга сузылып, телевизор карыйсыз һәм акча килгәнне көтәсез.

Ә ул байлыкны икеләтә арттырырга теләсәгез, башка тылсымлы сүзләр файдаланырга кирәк. Мәсәлән: "Төнге күктә ай тулсын, кесәмдә акча булсын". Аннан соң кредит аласыз да, сыра суыра-суыра телевизор карыйсыз. Тик лавр яфрагы турында онытырга ярамый!

Әгәр дә банк сезгә кредит бирергә теләми икән, Пермьдә яшәүче Валера кебек баерга тырышып карагыз. Ул бер ел эчендә миллионер булып киткән, чөнки кара икрадан баш тартып, ипи белән генә туклана башлаган. Ел ахырында исәпләп караса – миллион ярым экономия! Ә кара икра ашап яшәсә, ул аларны туздырып бетергән булыр иде! Ул шулай ук водопровод суы белән дә файдаланмаган, ә бу инде аена 500 сум дигән сүз! Валера шулай ук метрода йөрмәгән (бу – көненә 60 сум), чөнки Пермьдә метро юк. Шушы гади генә ысулларның аңа күпме акча китергәнен үзегез санап карагыз! Әлбәттә, ботинкалары тузып беткәнче табан астында лавр яфрагы йөрткән. Пермь түрәләре, бу керемнәр турында белгәч, аны эшсезлек буенча матди ярдәмнән мәхрүм иткәннәр. Өстәвенә, Валера яңа бизнес ачып җибәргән – ашаудан туктаган, ә монысы инде көненә 200–300 сум китерә! Хәтта, дөнья куйгач та үзе белән хушлашудан акча ясамакчы ул – мыштым гына елгада батып үлмәкче булып йөри...

Хәзер сәламәтлек турында. Бернинди дә табиблар, вакциналар һәм дарулар кирәкми! Кышын бәкедә коенасыз да кишер ашыйсыз! Кишер ул барча органнарга уңай тәэсир ясый. Кишер ашыйсыз һәм кабатлыйсыз: "И авыру, көчле авыру, сине карурман алсын. Авырулар миннән китсен, тәндә тазалык калсын!" Бу тылсымлы сүзләр бөтен нәрсәне дә дәвалый – бөсердән алып эч китүгә кадәр.

Ә тагын да күбрәк файдалы киңәшләр белергә теләсәгез, электричкада "Мин ничек авыруларны җиңдем һәм доллар миллионеры булып киттем" дигән китап алып укыгыз. Аны автор үзе сатып йөри. Ул әле сезгә контролёрлардан ничек оста итеп качарга да өйрәтер.

Сәламәт һәм бай булыгыз!






# ҮТКӘННӘРГӘ КАРЫЙК КАЕРЫЛЫП

Үзенең йөз еллык тарихында «Чаян» кемнән генә көлмәгән икән! 50 нче елларда аның кысаларына ул чактагы «неформаллар» – стилягалар эләгә. Ул заман өчен гадәти булмаган кием, чәч һәм сөйләшүләре белән башкалардан аерылып торган егет-кызларны шулай атаганнарар. Алар тыелган джаз яраткан, буги-вуги биегән һәм аларның һәрнәрсәгә үз фикере булган. Политикадан бик ерак торганнар.

Казан да киң таралган яшьләр шаукымыннан читтә калмаган. Алар телендә «Брод» дип аталган үзәк Бауман урамы буйлап стилягалар белән бергә ул чактагы мединститут студенты Василий Аксёнов та йөргәндер.

Стилягаларны, «буржуаз идеология» таратучы буларак, газеталарда һәм комсомол җыелышларында сүккәннәр, ә урамда аларга дружинниклар көн күрсәтмәгән. Ун елдан артык бу көрәшкә совет сатирик журналлары да үз өлешен кертеп барган. Дөресен генә әйткәндә, стилягалар үзләре дә кайчагында артыгын кыланып, моңа сәбәп биргәннәрдер.

Татар өлкә комитеты органы булган «Чаян» журналы да читтә калмый, әлбәттә. Ул еллардагы саннарны актарганда кызыклы нәрсәгә игътибар итәргә була. Карикатуралар караганда, советларча яшәргә теләмәүче персонажларга стиляга сыйфатлары бирелгән. Эшләмичә каңгырып йөрүче үсмерләрне, фарцовщикларны рәссамнар һәрвакыт кыска мыеклы, купшы чәчле, кыска тар чалбарлы, пальма рәсеме төшкән күлмәктән ясаганнар...



Чаян: Әйдәгез, санга узыгыз, ләкин исән чыгарга өметләнмәгез!



Әнә, кара: ничек матур бара – ул йөреше, кул-аягы...
Кыяфәте – гүя асыл чәчәк, ә асылы – шайтан таягы.















• • •

Психиатрда.

– Доктор, миндә депрессия, асылынасым килә!

– Әгәр ул күңелегезне күтәрсә, асылыныгыз...

• • •

Ирне табу гына җитми... Әле аның хыялы тормышка ашканын ышандырырга да кирәк!

• • •

– Сезне кисәтергә тиешмен – бүген бензин бәясе артты...

– Алайса миңа 30 литр кичәгесен салыгыз әле.

• • •

Үзем турында кыскача: эчмим, тартмыйм, кызлар белән йөрмим. Акчам юк...

• • •

Археологлар казу эшләрендә X гасыр эш коралларын тапкан. X гасыр кешеләре, күрәсең, эшләмәс өчен эш коралларын күмеп куйганнар.

• • •

Мин үземнең 28 яшемдә, әтиемнең ул яшьтә башына да килмәгән мал эшләп таптым: джинсы белән сагыз.

• • •

Элек: "Кайда тудың, шунда кирәгең чыкты" иде, ә хәзер: "Кая эләктең, шунда җаен таптың!"

• • •

Тикшерүче:

– Нинди максат белән, кайчан һәм кайда тудыгыз?

• • •

Ике хатын сөйләшә:

– Түбә ябучыны кичә машина бәреп киткән, – ди.

– Коточкыч, – ди икенчесе. – Түбәдә йөрү дә куркыныч хәзер.

• • •

– Син ишеттеңме – бензин тагын кыйбатланган!

– Сиңа барыбер түгелмени, машинаң юк бит синең.

– Ә зажигалка?


Михаил ЛАРИЧЕВ



Сергей АНДРИАНОВ


Валерий ТАРАСЕНКО




## ЮЛ ХОКУКЫ

Кадерле "Чаян"! Безнең үзәк урамнан үтә торган юл – бистәбезнең төп артериясе. Шуннан балаларыбыз мәктәпкә йөри, өлкәннәр – транспорт тукталышларына һәм кибетләргә. Быелгы явым-төшемгә бай елда кышын тездән артык кар ерып интегергә туры килә. Ләкин җирле администрация юл чистартырга уйламый да. "Аның хуҗасы бар – балансka аны куя алмыйсың", – дип аңлаталар безгә. Үзе чистартсын үзенең шәхси милкен, диләр.

Хуҗасы бит Мәскәүдә яши, аны юлның нинди хәлдә икәнлеге борчымый. Бу кыенлыктан чыгуны монда яшәүчеләр үзләре чишәргә булды – чөнки берәр нәрсә килеп чыкса, янгын сүндерүче машиналар да, ашыгыч медицина ярдәме күрсәтүчеләр дә, полиция дә килеп җитә алмаячак. Акча җыеп, грейдер яллаларга туры килгән. Бу эшкә инде 100 мең сум сарыф ителгән. Башка чара юк. Судлашып йөрү дә куркыныч. Әгәр дә юл хуҗасы юлга шлагбаум куйса һәм файдаланган өчен кыйммәтле бәя түләсә, әлеге 100 меңнәр күпкә очсыз тоелыр. Аның моңа хакы бар, диләр...

**КӨЕК бистәсендә яшәүчеләр.**

КАЗАН

## АДРЕСЛЫ ТУКЛАНДЫРУ

Кадерле редакция! Бар нәрсәгә экономия дигән тәгълимат мәктәп укучыларына да барып ирешә. Безнең шәһәр һәм районда күп балалы гаилә балаларын бушлай ашату туктатылыр, ахрысы. Әгәр дә әти-әниләре 1 нче апрельгә кадәр кирәкле документлар җыеп китерә алмасалар, алар махсус реестрга эләкмәячәкләр икән. Түрәләрнең фикеренчә, нәкъ менә хәзер адреслы туклландыруны оештыруның кирәге чыккан. Югыйсә мәктәпләрдәге ашатуга теләсә кем тыгыла, диләр.

Андый балалар районда барлыгы 1143, шуларның яртысы башлангыч сыйныфта укый, болай да бушка ашыйлар. Ә калганнарына кирәкле кәгазьләр җыю мәҗбүри һәм республиканың материаль ярдәм үзәге бүлегенә мөрәҗәгать итәргә киңәш ителә. Әллә ни баш ватасы түгел, мөгаен, кайберәүләр инде кул селтәгәннәрдер, бу буталчыктан чыгуны өмет итмиләрдер, балалар, димәк, түләүсез ашаудан мәхрүм калачак.

Менә шушы бюрократик "оптимизация"гә күз саласың да, ирексездән уйлап куясың: экономия ул – үзеңне кысу булып чыга, ә башкалар өлешенә керсәң, монысы инде – комсызлык.

**Ю. ГАЗИЕВА**

ТҮБӘН КАМА

**Александр БРЮХАНОВ**

# Кешечә булсын...

Сәүдә үзәгенең витриналары арасында ул күз иярмәслек тизлек белән чабып йөри иде... Әле уңнан, әле сулдан аның чәрелдек тавышы ишетелә иде...

– Кадерлем, әйдә келәм алыйк инде, бар кешенеке кебек булсын...

– Соң безнең ике келәм бар бит инде, кешенеке кебек...

– Ә мондые юк, – ди ул еламсыраган тавыш белән һәм чираттагы витрина янына ашыга, ә бер минуттан аннан тагын ишетелә:

– Җаным, бөтен стенага өй кинотеатры алып куйыйк инде, бөтен кешенеке кебек...

– Ә син анда билет сатып утырырсыңмы?

Халык арасында югалып тора да һәм бөтенләй көтелмәгән җирдән килеп чыга.

– Кадерлем, карале, нинди искиткеч кер юу машинасы! Әйдә алыйк, кешенеке кебек булсын инде...

– Соң берәү бар бит инде, – ди ире, – икенчесе нигә?..

– Дөнья хәлен белеп булмый бит... Кинәт ватылып куйса? Кешенеке кебек...

Өйгә кайтканда да ул башка кешеләрдә булган нидидер кирәкле әйберләр турында чәрелдәвен дәвам итте. Ул чәрелдәү машина салонын тутырды, приёмник тоташтыруның да кирәге юк иде...

Кинәт ир машинаны тимер рәшәткә белән әйләндереп алынган иске бакча янында туктатты. Алар салоннан чыктылар да рәшәткә янына килделәр.

– Кара, — диде ире.

– Нәрсә бу? – дип сорады хатын, чәрелдәвен туктатып.

– Бу – психиатрия хастаханәсе, – диде ир тыныч кына. – Сиңа кеше кебек яшәмәүче затларны күрсәтергә телим, чагыштырыр өчен...

Бакча буйлап тын гына уйчан кешеләр йөри иде. Бернинди чабыш, кычкырыш юк... Эскәмиядә ике ир коронавирусны кемнәр китергәне турында бәхәсләшеп утыра, масоннармы, әллә марсианнармы...

– Йә, ничек? — дип сорады ир.

– Әй, карале, нинди сырлы эскәмияләр, – дип чәрелдәде хатын. – Әйдә дачага шундыйларны алыйк, бөтен... – ул тынып торды, – кешенеке кебек булсын...




**Михаил ЛАРИЧЕВ**



## МОМЕНТАЛИСТ РӘССАМ ЗӨЛФӘТ ХӘЙРУЛЛИНга – 65 яшь

*...Күпләр үзен татарның бердәнбер шаржлар остасы дип йөртсә, якын дусты, үзе үк чеп-чи юмор остасы, танылган әдип Камил Кәримов аны милләтебезнең "моменталист рәссамы" дип атый. Ә әсәрләре, сурәтләү ысуллары белән машһүр Урманченың үзен сокландырган шәхес ул Зөлфәт Әнәс улы.*

**Якташы Рамазан ФӘРЗИЕВ.**

*Бүген рәссамнар буа буарлык булса да, секунд эчендә шарж ясаучылар бармак белән генә санарлык. Ә Зөлфәт, чыннан да, кыска гына арада теләсә кемнең көлкеле сурәтен эшләп тә бирә. Бигрәк тә сәнгать, әдәбият, театр әһелләрен яратып ясый. Инде шундыйларның 300 ләбе матбугат битләрендә дә дөнья күргән.*

*– Артист, язучы халкы тиз үпкәләүчән бит, тавышланып йөрүчеләр булдымы? – дип кызыксынам Зөлфәттән.*

*– Ошатмыйча ертып атканнары очраштыргалады. Андыйларда юмор хисе юк дип саныйм.*

**Журналист Атлас ГАФИЯТОВ**

*Уйнап-көлеп кенә йөри кебек,*
*Гармун уйный, җырлый, бии ул.*
*"Мин кем!" – диеп һичбер күкрәк какмый*
*Мактау – бүләк тиеш дими ул.*

**Язучы Нәҗибә САФИНА**

### Кайбер шәхесләргә язган эпиграмма һәм шаржлар



### Равил Шәрәфигә

Исемнәрем бик күп минем:
Рәсәйнең халык артисты
Равил Шәрәфи... Шәрә...
Шәрәгә бирген исемнәр
Мизерный льгота белән
Тәмам кесәгә бәрә.
Дальше, больше
санап китсәк,
Телгә алыйк Әҗәлне.
Алмаштырыйк исемнәрне –
Минем кебек зур шәхескә
Госслужащий җәлме?



### Илдар Хәйруллинга

Шәп артист та, режиссёр да...
Гениально! – сүзем юк...
Сәхнә өчен пьесаны да
Язмагае үзе үк?!



### Зилә Сөнгатуллинага

Сандугачлар сайрый
«чут-чут» дип,
Сәхнәләрне басты чүп, чүп, дип,
Рәхәтләнеп
өзелеп җырлыйм дисәң,
Татар операсы юк, юк, дип.
Милли исеме дөнья читендә.
Җырлаулары бар да чит телдә.
Татар артистларын читкә кагу –
Күнелләргә бигрәк читен лә...



### Рәшит Мостафинга

Атларым, йөгәннәрем,
Кызыл бөрлегәннәрем.
Күзем йомсам, күз алдымда
Дускаем, йөргәннәрең.



### Альберт Әсәдуллинга

Кайларда гына язмышлар
Йөртми татар баласын.
Мәскәү, Питерны яулады,
Аннан... Казан каласын!



### Мирсәет Сөнгатуллинга

Шатлыкта да, кайгыда да
Тыңлыйм сине, Мирсәет.
«Их, миңа да Ходай шундый
Моңлы тавыш бирсә», – дип.

Хәлил ФАИЛОВ




Бездә бик борынгы комган бар иде. Ул минем әбинең әбисенеке булган. Аны тәһарәт алу өчен кулланмаганнардыр, чөнки матурлыгы сокландыргыч – чып-чын артефакт. Күз алдына китерәсезме, үз гомерендә ул күпме күргән!.. Бөтен җире бакыр, нәфис борынлы, тоткычы матур итеп борып эшләнгән – музейга куярлык! Минем йортым, Аллага шөкер, барлык уңайлыклары белән төзелгән, шуңа күрә гаиләбезнең әлеге ядкаре бер почмакта тора һәм бүлмәбезнең ямен арттыра.

Бервакыт безгә таныш бер режиссёр килде дә, комганны күреп таң калды.

– Мин хәзер коллективлаштыру чоры турында кино төшерәм, анда комсомол Ильяс белән кулак ялчысы Вәзирәнең мәхәббәтен чагылдырырга кирәк. Менә моның шунда күренеп китүе бомба булачак! Биреп тор әле комганыңны? Аннан шул чорның аһәңе балкып тора...

– Ал да төшер! – дидем мин шатланып.

Күп тә үтмәде киностудиядән шалтыраттылар.

– Режиссёр Урманов Кара Шәкүр турында тарихи кино төшерә башлый. Сез беразга үзегезнең комганыгызны биреп тормассызмы, – диләр. – Ул шул чорның рухын бик яхшы биреп торыр иде...

– Алыгыз, – дидем. – Төшерегез рәхәтләнеп!

Бер ай чамасы югалып торганнан соң комган яңадан үз почмагына кайтып җитте. Атна-ун көн тормагандыр, режиссёр Бәйрәмов шалтырата.

– Карале, мин синең комганны "Ат карагы" фильмын төшергәндә күрдем. Исләрем китеп, хыялга чумып "Комганлы теләкләр" дигән сценарий язып ыргыттым.

– Нәрсә турында була инде ул фильм?

– Кыскасы, үткән гасыр башында бер сәүдәгәр, безнекеләрдән, париж аукционында бакыр комган сатып ала.

– Ул анда ничек барып эләккән?

– Анысы әһәмиятле түгел. Шунысы мөһим: ул тылсымлы булып чыга. Сыпырып кына җибәрәсең – бар теләгең кабул була. Менә шул тирәдә сюжеты куертыла. Монда сөяркәләр дә, бандитлар да, җыен юк-бар, һәм Париж... "Кабан күле сере" – пүчтәк! Биреп торырсыңмы комганыңны? Тиз кирәк иде югыйсә Нәфигуллин "Туган авылымның җылы җилләре" дигән күп серияле гаилә риваяте төшерергә ниятләп ята икән. Башласа, комганны күрмәячәкмен...

Бәйрәмовка комганны бирдем дә уйга баттым: нигә бөтен фильмнар гел элекке заман турында? Бүгенге көннәрне төшерсәң, темалар тулып ята бит: күпме сюжетлар, ызгыш-талашлар, төрле холыклы кешеләр – теләмәсәң дә үзләре кадрга керергә ыргылып торалар! Минем комган аркасында килеп чыга түгелме соң бу очраклар, төп сәбәпче шулмы әллә?.. Шундый нәтиҗәгә килдем: әйләнеп кайтуы белән чоланга яшереп куям һәм берәүгә дә бирмим.

Ләкин минем ниятем барып чыкмады. Комган югалды. Ул кулдан-кулга күчеп, бер фильмнан икенчесенә китеп, үз тормышы белән яши башлады. Аны сорап берәү дә шалтыратмады.

Бер елдан соң телефонда бер таныш тавыш – Бәйрәмов икән.

– Бәла! Казанны алу фильмын төшереп йөргәндә синең комганыңны урладылар... Кайсыдыр хәшәрәт, төсле металлга кызыгып чәлдергән... Нишләрбез инде хәзер комгансыз... Безне гафу ит инде...

Әлбәттә, мин аны кичердем, гәрчә гаиләбезнең реликвиясе буларак бик кызгансак та... Киночылар да кызганыч, комгансыз ни эшли алалар инде алар? "Хәер, – дип уйладым мин, – бәлки шушы хәлдән соң заманыбызга лаек фильмнар күренә башлар..."

ИЛФАК

## Пәп иттерсә ярый да...

Дуслар, яз җитә! Яз дигәч тә беренче булып мәхәббәт искә төшә. Төшәме? Әлбәттә, яратмаган кеше юктыр. Яисә яратып карамаган. Исегезгә төшерегез, җәйге кич, җиләс һава һәм син кыз озатасың. Кыз дигәннән. Кызлар, әйтегез әле, нигә сез кичен суытачагын белеп, юка күлмәк белән чыгасыз соң? Аннан, туңудан тешләре бер-берсенә бәрелеп, трактордай дырылдап торган егетләрнең суыктан саклаучы соңгы курткасын салдырып аласыз да, елмаеп кына рәхмәт дип куясыз. "Рәхмәт сиңа..." Шул вакыттагы безнең уйларны беләсегез киләме, кызлар? Әйтмәм дигән идем, егетләр, әйттерәләр инде. Башта ике генә уй. Йә кочаклаттырып җылына алсам ярар иде, йә куртканы биреп, тизрәк кереп югалсын иде. Ярый ла аңлый белсә. Алар бит әле озак кына капка төбендә, мин тәүфыйклы кыз, миңа тиярга ярамый дип, таңга кадәр безнең курткадан утыралар. Нинди тәүфыйклы инде сез? Күрәләтә торып катырып интектерүчеләр.

Ләкин үзебездә дә гаеп бар инде. Әгәр кереп киткәндә бит очыннан гына пәп иттерсә, бу капка төбендә гомерең буе бер футболкадан торырга риза... Менә шулай ул яшьлек мәхәббәте. Хәзерге акылым булса, ике куртка күтәреп чыгар идем. Хатын гына кызлар янына чыкканны яратмый...





САТИРА һӘМ ЮМОР ЖУРНАЛЫ

1923 елдан чыга.

№ 3 (1916) март 2022

Баш редактор:
Р. И. ХӘЛИЛУЛЛОВ
Баш рәссам: А. АЛЁШИН
Баш редактор урынбасары: Г. ЗАМАЛДЫНОВА
Үсеш бүлеге: П. СТАРОВЕРОВ
Редакторлар: Р. АБЗАЛОВ,
Л. САФИУЛЛИНА, А. ХӘМЗИН
Сайт редакторы: Л. ӘХМӘТОВА
Корреспондент: Г. СӨНГАТУЛЛИНА
Дизайнер: Л. ФӘЛӘХОВА

Учредителе һәм нәшер итүчесе «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.

420047, Казан шәһәре, Академическая урамы, 2

Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләре агентлыгы ярдәмендә оештырылган.

Журнал Роскомнадзор идарәсендә теркәлде.
Теркәлү саны һәм вакыты:
ПИ № ФС77-44364, 23 март, 2011 ел.

«Журналга «Почта России» каталогы, йә https://podpiska.pochta.ru онлайн аша язылa алалар.

Язылу индекслары:
РТ – П2438 (тат), П2440 (рус);
РФ – П7088 (тат), П7087 (рус).

Редакция материалларны авторларның ризалыгыннан башка редакцияләү-төзәтү хокукына ия.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» типографиясендә басылды.
Басылып чыгу: 25.02.2022 ел.
Тираж – 3265 Заказ О-0496


Редакциянең адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Белешмәләр өчен телефоннар:
(843) 222-06-00, 222-05-54.

E-mail: chayan@bk.ru
Сайт: chayan-journal.ru
Бәясе ирекле

16+

# Уйна да, уйла да!




Ринат АБЗАЛОВ төзеде.




1. Ремонттан соң ишегалдында калган ком өеме нәрсәгә әверелә?

2. Золушка (Көл кызы) турындагы әкият нәрсә турында?

3. Теләсә нинди юк әйбердән нинди акыллы фикер чыгарып була?

4. Гаиләдәге ызгыш нәрсә ул?

5. Балачак кайчан була?

6. Эчкечене икенче төрле ничек исемләп була?

7. Гөнаһлылар нәрсәгә өмет итә?

## ҖАВАПЛАР

1. Мәче продукциясе складына. 2. Кызларның төн уртасына хәтле чибәр булып күренү турында. Аннан соң ничек булса да ярый. 3. Соңыннан: "Ә хәзер нәтиҗә ясагыз", – дип өстәп куярга кирәк. 4. Ике homoның кайсысы sapiens икәнен ачыклау бәхәсе. 5. Мәчегез сездән өлкәнрәк булганда. 6. Гадәттән тыш аек булмаган кеше. 7. Тәмугның резина түгеллегенә.

Сынамышларны Гүзәл СӘНГАТУЛЛИНА әзерләде.

**Ч**айнвордны чишегез, номерланган шакмакларда җыр исемен укыгыз. Журналыбызның 2 нче санындагы чайнвордның тикшерү сүзе – **«КАЙТ, ИРКӘМ СӘРВИНАЗ»**

Беренче булып дөрес җавап җибәрделәр:

**Г. БАҺАВЕТДИНОВ** (Чаллы),
**З. ЯРУЛЛИНА** (Апас),
**Л. ГЫЙЛӘҖИЕВА** (Казан),
**С. ШӘЙХУЛЛИН** (Казан).

Җиңүчебез – Апастан **Зәйнәп ЯРУЛЛИНА!**

*Елена ХИТРОВА*





Гадәттә, карикатура ирләр эше дип санала. «Чаян» тәҗрибәсе моның киресен күрсәтә. Төрле елларда журнал битләрендә күп кенә гүзәл затларыбыз ясаган рәсемнәр басылып чыкты. Шуларның берсе – **Елена ХИТРОВА**. Элегрәк ул журнал белән бик актив хезмәттәшлек итә иде, ләкин соңгы елларда аның карикатуралары сирәк күренә. Хатын-кызлар бәйрәме уңаеннан Елена «Чаян» укучыларына вернисажын бүләк итәргә булды.







– Каян килеп тулганнар...

4612750670080